Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«18» ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Киекле авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Киекле авыл җирлегенең Киекле авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Киекле авылында су җыю скважиналарын карап тоту өчен, эшләр һәм хезмәтләр башкару, товарлар сатып алу.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, юл кырыйларына таш, ватылган кирпеч, грунт, вак таш, ком түшәү (сатып алу, ташу, җәю).

Киекле авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәтләр, товарлар сатып алу.

Киекле авылының ике зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агачларны кисү, үлән чабу).

Киекле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу (янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, урнаштырылган гидрантларны ремонтлау).

Киекле авылында спорт-массакүләм һәм мәдәни-массакүләм чараларны оештыру һәм үткәрү.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.А.Заһертдинова

Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Заһертдинова